# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Сакон авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 16 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сакон торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендәге Сакон торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) урамнарны яктыртуны карап тоту;
2) юлларны карап тоту һәм төзү;
3) су белән тәэмин итүне карап тоту;
4) территорияне төзекләндерү;
5) ККК мәйданчыкларын карап тоту».

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Лебяжье авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Лебяжье авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Лебяжье авыл җирлеге башлыгы Д.Ә.Гыйләҗев